**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Ятмас-Дусай авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**03 ноябрь 2021 ел** **№ 18**

**«Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлегенең Ямбулат-Пустошь авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2021 елның 18 ноябренә 11 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлегенең Ямбулат-Пустошь авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Ямбулат-Пустошь авылы, Яшел урамы, 16 нче йорт адресы буенча урнашкан торак йорт бинасында үткәрергә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлегенең Ямбулат-Пустошь авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Ямбулат-Пустошь авылында Яшел урамына вак таш җәю ; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

-Ямбулат-Пустошь авылы юлларын кардан чистарту (килешү буенча түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Ятмас-Дусай авылы Башкарма комитетын билгеләргә.
4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.
5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Ятмас-Дусай авыл җирлеге башлыгы: Ф.Х.Гарифуллина